ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТЕЛӘНЧЕ ТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

КАРАР

«03» апрель 2024 ел Теләнче Тамак авылы № _10_

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге составына керүче Таулык авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 09 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2023 елның 09 ноябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге Таулык авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге Таулык авылында гражданнар җыенын билгеләү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Тукай муниципаль районы «Теләнче Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Теләнче Тамак авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге Советының 2019 елның 29 октябрендәге 47/2 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге составына керүче Таулык авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 09 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2023 елның 09 ноябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге Таулык авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча 2024 елның 14 апрель 16.00 сәгатькә гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез үзгәрешләр кертергә ризамы:

1) түбәндәге редакциядә бәян итеп, гражданнар җыенына чыгарылган һәм кабул ителгән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге составына керүче Таулык авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 09 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына:

“- су белән тәэмин итү һәм су бүлү системаларын, суэтем башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Таулык авылы Луговая урамындагы су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау, (материаллар, җиһазлар сатып алу, торбаларны алыштыру, торбалар урнаштыру, махсус техника хезмәтләре күрсәтү) »;

«- тукталыш комплексларын ремонтлау, сатып алу һәм урнаштыру ( Таулык авылында тукталыш комплексларын ремонтлау)”

2) түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2023 елның 09 ноябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге Таулык авылында гражданнар җыены карарына:

“- су белән тәэмин итү һәм су бүлү системаларын, суэтем башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Таулык авылы Луговая урамындагы су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау, (материаллар, җиһазлар сатып алу, торбаларны алыштыру, торбалар урнаштыру, махсус техника хезмәтләре күрсәтү) ».

«- тукталыш комплексларын ремонтлау, сатып алу һәм урнаштыру ( Таулык авылында тукталыш комплексларын ремонтлау)”

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Теләнче Тамак авыл җирлеге, Таулык авылы, Нурми Шарипов ур., 40 йорт (мэдэнят йорты бинасы).

4. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә махсус мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarsatan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тукай муниципаль районы
Теләнче Тамак авыл җирлеге Башлыгы Р.Ш. Назметдинов

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ТУКАЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ * ОГРН 1061682004717 Исполнительный комитет Тлянче-Тамакского сельского поселения ИНН 1639032294